**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань

от 09.12.2013 №725-п

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга карата төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентын раслау турында**

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26.12.2008 ел, № 294-ФЗ Федераль законның 5 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт вазифаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында” 16.05.2011 ел, № 373 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга карата төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентын (алга таба – административ регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Административ регламент раслау турында” 23.03.2010 ел, № 211 боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу административ регламентның үтәлешен контрольдә тотуны Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгына (Т.Н.Гыйльметдинов) йөкләргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алуны тәэмин итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Х.Низамовка йөкләргә.

Министр А.Г.Сидоров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый
ресурслар министрлыгының
09.12.2013 ел,
№ 725-п боерыгы
белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫНДА ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ ҖИР АСТЫ КИШӘРЛЕКЛӘРЕНӘ КАРАТА ҖИР АСТЫ БИЛӘМӘЛӘРЕН ГЕОЛОГИК ӨЙРӘНҮГӘ, АЛАРДАН РАЦИОНАЛЬ ФАЙДАЛАНУГА ҺӘМ АЛАРНЫ САКЛАУГА КАРАТА ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ВАЗИФАСЫН ҮТӘҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга карата төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең бу Административ регламенты (алга таба – Регламент) “җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга карата үзәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру” дәүләт вазифасын үтәүдә (алга таба – дәүләт вазифасы) Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы (алга таба – ТР ЭТРМ) вазифаи затларының гамәлләре вакытларын һәм тәртибен билгели.

Җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга карата төбәк дәүләт күзәтчелеге (алга таба – дәүләт күзәтчелеге) төбәк дәүләт экология күзәтчелегенең бер өлеше булып тора, аны гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 09.12.2013 ел, № 721-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламенты (алга таба – Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча административ регламент) нигезендә билгеләнгән.

1.2. Дәүләт вазифасы түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 26.01.2009, № 4, 445 ст.);

30.12.2001 ел, № 195-ФЗ Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 07.01.2002, № 1 (1 өлеш), 1 ст.);

30.11.1994 ел, № 51-ФЗ Россия Федерациясе Граждан кодексы (алга таба – РФ ГК) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 05.12.19, № 32, 3301 ст.);

25.10.2001, № 136-ФЗ Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 29.10.2001, № 44, 4147 ст.,);

“Җир асты биләмәләре турында” 21.02.1992, № 2395-1 Россия Федерациясе законы (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 06.03.1995, № 10, 823 ст.);

“Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 10.01.2002, № 7-ФЗ Федераль закон (алга таба – №7-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 14.01.2002, № 2, 133 ст.);

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26.12.2008, № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 29.12.2008, № 52 (1 өлеш), 6249 ст.,);

“Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 02.05.2006, № 59-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 08.05.2006, № 19, 2060 ст.);

“Җир асты биләмәләреннән файдалануны лицензияләү тәртибе турында нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында” 15.07.1992 ел, № 3314-1 Россия Федерациясе Югары Советы карары (алга таба – № 3314-1 РФ Югары Советы карары) (“Ведомости СНД һәм ВС РФ”, 20.08.1992, № 33, 1917 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Файдалы казылмаларны эзләү һәм аларны чыгаруны хәл итүче предприятиеләр тарафыннан федераль һәм территориаль геологик мәгълүмат фондларына дәүләт хисабын тапшыру тәртибен раслау турында” 28.02.1996, № 215 карары (“РФ законнар җыентыгы”, 18.03.1996, № 12, 1110 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга дәүләт контрольлеге турында нигезләмәне раслау хакында” 12.05.2005, № 293 карары (“РФ законнар җыентыгы”, 16.05.2005, № 20, 1885 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт контрольлеген (дәүләт экология контрольлеген) гамәлгә ашыру турында” 27.01.2009, № 53 карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 02.02.2009, № 5, 625 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Федераль дәүләт экология контрольлегенә кергән объектлар исемлеге турында” 31.03.2009 ел, № 285 карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 06.04.2009, № 14, 1668 ст.);

Россия Федерациясе Статистика буенча дәүләт комитетының “Россия ТРМ тарафыннан файдалы казылма запасларына, геология-разведка эшләренә һәм аларны финанслауга, судан файдалануга һәм әйләнә-тирә мохитне пычраткан өчен исәпләнгән түләүләргә статистик күзәтү оештыру өчен статистик чараларны раслау турында” 13.11.2000, № 110 карары (“Вопросы статистики” № 9, 2002);

Татарстан Республикасы Конституциясе (“Ватаным Татарстан”, № 85-86, 30.04.2002);

15.01.2009, № 5-ТРЗ Татарстан Республикасы Экология кодексы (алга таба – ТР ЭК) (“Республика Татарстан”, № 10, 20.01.2009);

“Җир асты биләмәләре турында” 25.12.1992, № 1722-XII Татарстан Республикасы Законы (алга таба – “Җир асты биләмәләре турында” ТРЗ) (“Республика Татарстан”, № 14, 22.01.2000);

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 12.05.2003, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (“Республика Татарстан”, № 99-100, 17.05.2003);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләре арендаторлары тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмалары һәм көнкүреш кое һәм скважина җайланмаларын төзү тәртибен раслау турында” 29.02.2012, № 171 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 06.04.2012, № 26, 0859 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә үзләренә бирелгән тау өлеше һәм (яки) геологик урыннар чикләрендә файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару яки уртак лицензия нигезендә файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгаруны хәл итүче җир асты биләмәләреннән файдаланучыларның үз җитештерүе һәм технологик ихтыяҗлары өчен гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгару тәртибен раслау турында” 21.12.2011, № 1042 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 17.01.2012, № 4, 0127 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында” 04.11.2011, № 917 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 14.12.2011, № 47, 2507 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлекләрен раслау

турында” 21.09.2011, № 784 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 26.10.2011, № 40, 2038 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 ел, № 325 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы”, 27.07.2005, № 28, 0654 ст.);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын башкаруның административ регламентын раслау турында” 09.12.2013, №721-п боерыгы.

1.3. Дәүләт вазифасын үтәүче булып ТР ЭТРМ тора. Дәүләт вазифасын турыдан-туры үтәүчеләр булып ТР ЭТРМ Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе, территориаль идарәләре тора.

Дәүләт вазифасы турыдан-туры ТР ЭТРМ вазифаи затлары – ТР ЭТРМ министры (алга таба – министр), ТР ЭТРМ министр урынбасарының (алга таба – министр урынбасары) тикшерү үткәрүгә боерыгы нигезендә вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторлары (алга таба – вазифаи затлар) тора (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.09.2011, № 784 карары нигезендә).

Вазифаи затлар дәүләт вазифасын үтәгәндә прокуратура органнары, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, гражданнар белән берлектә эшли.

1.4. Дәүләт күзәтчелеге объекты булып:

– федераль законнар нигезендә башкача билгеләнмәгәндә, эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларының, шул исәптән гадәти ширкәт әгъзаларының, чит ил гражданнарының, юридик затларның җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлегеннән файдалануга бәйле хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек тора.

1.5. Дәүләт күзәтчелегенең предметы.

Планлы тикшерү предметы булып җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек процессында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү тора.

Планнан тыш тикшерү предметы булып җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек процессында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, ТР ЭТРМ күрсәтмәләрен үтәү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүне кисәтү, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгуын кисәтү, мондый зыянның аянычлы нәтиҗәләрен бетерү буенча чараларны үтәү тора.

1.6. Вазифаи затларның дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырудагы хокуклары һәм бурычлары

1.6.1. Табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары булып торучы ТР ЭТРМ вазифаи затлары Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) нигезле язмача гарызнамәләр нигезендә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм гражданнардан тикшерү барышында кирәкле мәгълүматларны һәм документларны соратып алырга;

2) контрольлек чараларын үткәрү максатыннан чыгып, хезмәт таныклыгын һәм министрның (министр урынбасарының) тикшерү билгеләү турында боерыгы (әмернамәсе) күчермәсен күрсәтеп, оешу-хокукый рәвешенә һәм милекчелек рәвешенә бәйсез рәвештә, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан хуҗалык яки башка төрле эшчәнлек башкарганда файдаланыла торган территориядә, бинада, бүлмәдә, корылмада, шул исәптән чистарту корылмаларында комачаулыкларсыз булырга, башка зарарсызландыру җайланмаларын, контрольлек чараларын, техник һәм транспорт чараларын, җиһазлар һәм материалларны тикшерергә, шулай ук күзәтчелек буенча кирәкле тикшеренүләр, сынаулар, тикшерүләр, экспертизалар һәм башка чаралар үткәрергә, үлчәмнәр алырга;

3) тикшерү үткәрүне № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә прокуратура органнары белән килештерү турында гариза җибәрергә;

4) юридик зат җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәрләре, шәхси эшмәкәр белән әңгәмә корырга, алардан тикшерү предметына керә торган аңлатмалар алырга;

5) тикшерү үткәрүгә үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган, тикшерелә торган затларның аффилирлы затлары булып тормаган экспертларны, эксперт оешмаларын тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә.

1.6.2. Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторлары булып торучы ТР ЭТРМ вазифаи затлары тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне бурычлы:

1) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, юкка чыгару вакытларын күрсәтеп, ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында һәм (яки) кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затлар милкенә, дәүләти яки муниципаль милеккә зыян китерүне кисәтү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгуын кисәтү чаралары, шулай ук федераль законнарда күздә тотылган башка чаралар үткәрү турында күрсәтмәләр бирергә;

2) ачыкланган бозуларны юкка чыгару, аларны кисәтү, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләренә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлеген тәэмин

итүгә зыян китерүне кисәтү, табигый һәм техноген характердагы гадәттәге тыш хәлләрнең килеп чыгуын кисәтү буенча контрольлек чаралары күрү, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чаралары күрергә;

3) мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм бозуга юл куймау вәкаләтләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз вакытында һәм тулы күләмендә үтәргә;

4) тикшерелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, Россия Федерациясе законнарын үтәргә;

5) тикшерүне, билгеләнеше нигезендә, Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министрының (алга таба – министр) тикшерү үткәрү турында боерыгы яки Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министрының беренче урынбасары (алга таба – министрның беренче урынбасары) әмернамәсе нигезендә хәл итәргә;

6) тикшерүне фәкать хезмәт бурычларын үтәгән вакытта, урынга чыгып тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, министр (министр урынбасары) боерыгы күчермәсен һәм № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә күздә тотылган очракта – тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында документ күчермәсен күрсәтеп хәл итәргә;

7) тикшерү үткәргәндә юридик зат җитәкчесенә, башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрүне карап торуга комачауламаска һәм тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

8) тикшерү үткәргәндә карап торган юридик зат җитәкчесенә, башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына керүче мәгълүматлар һәм документлар тапшырырга;

9) юридик зат җитәкчесен, башка вазифаи затын яки вәкаләтле вәкилен, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

10) ачыкланган бозу фактлары буенча кабул ителә торган карарлар билгеләүдә бу чараларның бозуларга туры килүен, аларның кешеләр тормышы, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) өчен, дәүләт куркынычсызлыгы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгу ихтималына туры килү-килмәвен исәпкә алу, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймаска;

11) үз гамәлләренә Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан шикаять белдерелгәндә, гамәлләрнең нигезлеген расларга;

12) № 294-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тикшерү үткәрү вакытларын сакларга;

13) юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән Россия Федерациясе законы нигезендә тапшыру күздә тотылмаган документларны һәм башка мәгълүматларны таләп итмәскә;

14) урынга чыгып тикшерү үткәрер алдыннан юридик зат җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече белән тикшерү үткәрүгә нигез итеп алынган бу Регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

15) тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәренә үткәрелгән тикшерү турында язып куярга.

1.6.3. Табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары булып торучы ТР ЭТРМ вазифаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы була алмый:

1) мәҗбүри таләпләр үтәүне тикшерергә, бу таләпләр ТР ЭТРМ вәкаләтләренә кермәгәндә;

2) юридик зат җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаганда, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздырырга, гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә зыян китерү буенча, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу сәбәпле, тикшерү үткәрү очрагыннан тыш;

3) җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләрен һәм җитештерү мохите объектларын тикшерү пробаларын, документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләрен тапшыруны таләп итәргә, тикшерү объекты булып тормаганда, яки тикшерү предметына кермәгәндә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен тартып алырга;

4) үрнәкләрне сайлап алу турында беркетмәләрне рәсмиләштермичә генә җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләрен һәм җитештерү мохите объектларын тикшеренү пробаларын, продукция үрнәкләрен алырга, илкүләм стандартлар, үрнәкләр алу кагыйдәләре, тикшеренүләр-сынаулар, үлчәүләр ысуллары, техник регламентлар яки алар үз көченә кергәнче гамәлдә булып килгән башка норматив-техник документлар һәм тикшеренүләр, сынаулар, үлчәүләр алу кагыйдәләре һәм ысуллары нигезендә билгеләнгәннән артып киткән күләмдә пробалар алырга;

5) тикшерү нәтиҗәсендә алынып, дәүләт сере, коммерция сере, хезмәт урынындагы сер, закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торган мәгълүмат таратырга, Россия Федерациясе законында күздә тотылган очраклардан тыш;

6) билгеләнгән тикшерү үткәрү вакытына сыешмаска;

7) юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә үзләре хисабына контрольлек чаралары үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирергә.

1.7. Үзләренә карата дәүләт күзәтчелеге чаралары уздырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.7.1. Юридик зат җитәкчесе, башка вазифаи заты, вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәрүне карап торырга, тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) ТР ЭТРМдан, вазифаи затларыннан тикшерү предметына кергән һәм № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә тапшырылырга тиешле мәгълүмат алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән килешүе яки килешмәве, шулай ук ТР ЭТРМ вазифаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтергә;

4) тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән ТР ЭТРМ вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына), Россия Федерациясе законы нигезендә, административ тәртиптә (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә.

1.7.2. Юридик зат җитәкчесе, башка вазифаи заты, вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә бурычлы:

1) тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазифаи затлар тарафыннан сорала торган документларны һәм материалларны тапшырырга, шулай ук тикшерү предметына кергән сораулар буенча телдән һәм язмача аңлатмалар бирергә;

2) тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазифаи затларның эшчәнлек процессында файдаланыла торган территориягә, бина, корылма, бүлмә, җиһаз, транспорт чараларына комачаулыксыз керүне тәэмин итәргә;

3) мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештырырга һәм үткәрүгә җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең булуын яки үзенең булуын тәэмин итәргә.

1.8. Дәүләт вазифасын үтәү нәтиҗәсе.

Тикшерү үткәрүче ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан планлы, планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге документлар тутырыла:

юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләрен саклау өлкәсендә законны үтәүне тикшерү акты – билгеләнгән рәвештә ике нөсхәдә, тикшерү актының үрнәк рәвеше Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентының №1 кушымтасында китерелгән;

ТР ЭТРМ вәкаләте чикләрендә РФ КоАП күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә (бозу факты ачыкланган очракта);

җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләрен саклау өлкәсендә закон бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә (бозу факты ачыкланган очракта).

ТР ЭТРМга гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү дәүләт вазифасын үтәүгә нигез булып торган

очракта мөрәҗәгать итүчегә (алга таба – мөрәҗәгать итүче) закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт вазифасын үтәү нәтиҗәләре буенча җавап җибәрелә.

ТР ЭТРМ вазифаи затлары мәҗбүри таләпләрне бозуларны тикшергәндә Россия Федерациясе законында күздә тотылган вәкаләтләре чикләрендә ачыкланган бозуларны юкка чыгару, аларны кисәтү гражданнар тормышы, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), дәүләт иминлегенә зыян китерү ихтималын кисәтү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең килеп чыгуын кисәтү буенча контрольлек чаралары күрә; шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чаралары күрә.

Күзәтчелек чаралары нәтиҗәләре буенча затның гамәлләрендә (гамәл кылмау) административ хокук бозу билгеләре булганда, гаепле затка карата РФ КоАПта билгеләнгән тәртиптә административ эш кузгатыла.

Тикшерү үткәргәндә тикшерелә торган затның эшчәнлегенең гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), дәүләт иминлегенә зыян китерү белән, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне китереп чыгару куркынычы белән янавы яки зыян китерүе ачыкланган очракта ТР ЭТРМ, РФ КоАП билгеләнгән тәртиптә зыян китерүгә юл куймау буенча яки, затның эшчәнлеген вакытлыча тыюга кадәр, гражданнарның тормышы, сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохит өчен хәвеф тудырырдай продукцияне әйләнештән алу һәм гражданнарга, шулай ук башка юридик затлар, шәхси эшмәкәрләргә зыян килү куркынычы һәм аны кисәтү ысуллары турында теләсә нинди уңайлы ысул белән җиткерү буенча кичекмәстән чаралар күрә.

Күзәтчелек чараларын үткәрү барышында җинаять билгеләре ачыкланганда, җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләрен саклау өлкәсендә закон бозуга бәйле материалларны, җинаять эшләре кузгату турында мәсьәләне хәл итү өчен, вәкаләтле органнарга җибәрү турында мәсьәлә карала.

## 2. Дәүләт вазифасын үтәү тәртибенә карата таләпләр

2.1.Дәүләт вазифасын үтәү турында мәгълүмат җиткерү тәртибе

2.1.1.Бу Регламент ТР ЭТРМның Интернет челтәрендәге рәсми сайтына – www.eco.tatar.ru урнаштырыла.

2.1.2. ТР ЭТРМ урнашу урыны: Казан ш., Павлюхин ур, 75 й.

ТР ЭТРМ белешмәләр алу өчен тел.: 267-68-01, 267-68-70.

Мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен электрон адрес: http:/eco.tatar.ru/.

ТР ЭТРМ структур бүлекчәләренең адреслары һәм телефоннары 2.1 таблицада китерелә.

2.1. таблица – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының территориаль органнары турында мәгълүматлар

| Территориаль орган | Адресы | Хезмәт күрсәтелә торган территорияләр | Телефоны |
|---|---|---|---|
| Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – ДЭКИ) | 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 | Татарстан Республикасы | 267-68-67<br>264-34-89 |
| Үзәк территориаль идарә (алга таба – ҮТИ) | 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 | Казан ш.,<br>Биектау муниципаль районы (алга таба – МР),<br>Лаеш МР,<br>Питрәч МР,<br>Югары Ослан МР,<br>Балык Бистәсе МР,<br>Саба МР,<br>Теләче МР,<br>Зеленодол МР | 291-04-30<br>291-05-95 |
| Төньяк территориаль идарә | 422000, Арча ш.т.б., Интернациональная, 41 | Арча ш.<br>Әтнә МР,<br>Арча МР,<br>Балтач МР,<br>Кукмара МР | (8-84366)<br>3-21-61 |
| Идел аръягы территориаль идарәсе | 422430, Буа,<br>Р. Люксембург ур., 159/1 й. | Буа,<br>Буа МР,<br>Чүпрәле МР,<br>Апас МР,<br>Кайбыч МР,<br>Кама Тамагы МР,<br>Тәтеш МР | (84374)<br>3-11-02<br>3-34-46 |
| Идел-Кама территориаль идарәсе | 422980, Чистай ш., Фрунзе ур., 97 А | Чистай ур.,<br>Аксубай<br>Алексеевск МР,<br>Әлки МР,<br>Спас МР,<br>Чистай МР,<br>Яңа Чишмә МР | (84342)<br>5-35-19<br>5-03-68 |
| Кама аръягы территориаль идарәсе | 423552,Түбән Кама ш.,<br>Красный ключ б., Набережная ур., 7 й. | Түбән Кама ш.,<br>Түбән Кама ш. МР,<br>Зәй МР,<br>Сарман МР | (88555)<br>45-66-56<br>43-90-70 |
| Кама буе территориаль | 423838,Чаллы ш.,<br>Җиңүнең 40 | Чаллы ш.<br>Әгерже МР, | (8-8552)<br>59-36-39 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| идарәсе | еллыгы, 64 | Менделеев МР,<br>Минзәлә МР,<br>Тукай МР,<br>Мамадыш МР,<br>Алабуга МР,<br>Актаныш МР | 59-50-46 |
| Ык буе территориаль идарәсе | 423330, Азнакай ш., Шоссе ур., 6 й. | Азнакай МР,<br>Актүбә ш.т.б.<br>Азнакай МР,<br>Баулы МР,<br>Мөслим МР,<br>Ютазы МР | (8-85592)<br>2-39-86<br>(8-85592)<br>51-5-38 |
| Көньяк-Көнчыгыш территориаль идарә | 423450, Әлмәт ш., Әминов ур., 9 А й. | Әлмәт ш.,<br>Әлмәт МР,<br>Бөгелмә МР,<br>Лениногорск МР,<br>Нурлат МР,<br>Чирмешән МР | (8-8553)<br>33-03-25<br>33-03-27 |

2.1.3. ТР ЭТРМга дәүләт вазифасын үтәү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр һәм документлар җибәрү өчен почта адресы: 420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75 й.

2.1.4. ТР ЭТРМ (ТР ЭТРМ ҮТИ кертеп) эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 сәгатькәчә;

җомга – 9.00 дән 16.45 сәгатькәчә.

Төшке аш вакыты 12.00 дән 12.45 сәгатькәчә.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Территориаль органнарның эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькәчә;

җомга – 8.00 дән 15.45 сәгатькәчә.

Төшке аш вакыты 12.00 дән 12.45 сәгатькәчә.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.1.5. ТР ЭТРМ, структур подразделениеләренең һәм территориаль органнарының урнашу урыны, телефоннары һәм эш графигы турында мәгълүмат Интернеттагы сайтында (http://eco.tatar.ru/) һәм ТР ЭТРМ фойесындагы, территориаль органнар коридорларындагы, холлары, фойесындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган. Әлеге мәгълүмат белән шулай ук телефоннар аша танышырга була:

министрның кабул итү бүлмәсе – 267-68-01;

ТР ЭТРМ ДЭКИ – 267-68-67.

Дәүләт вазифасын үтәү тәртибе турында мәгълүматлар Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентларының бердәм реестрына кертелә һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Интернет челтәрендәге рәсми

сайтына (http://mert.tatarstan.ru) һәм ТР ЭТРМ рәсми сайтына (http://eco.tatar.ru) урнаштырыла.

Дәүләт вазифасын үтәү тәртибе турында мәгълүмат дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлар тарафыннан тапшырыла:

– турыдан-туры ТР ЭТРМ һәм территориаль органнары белгечләре тарафыннан шәхсән кабул итү кысаларында;

– язмача рәвештә;

– электрон почта аша;

– “Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы” республика дәүләт мәгълүмат системасы (http://uslugi.tatar.ru.) (алга таба – Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) аша.

Дәүләт вазифасын үтәү тәртибе турында мәгълүмат гражданнарны кабул итү хәл ителә торган ТР ЭТРМ һәм аның территориаль органнары биналарындагы стендларга урнаштырыла.

2.1.6. Халыкка телдән мәгълүмат җиткерү массакүләм мәгълүмат чаралары – радио, телевидение аша хәл ителә. Радио, телевидение аша мәгълүмат җиткерүгә җаваплы белгечләрнең чыгышлары министр белән килештерелә.

**2.2. Дәүләт вазифасын үтәү вакытлары һәм вакыт аралыклары**

2.2.1. Тикшерү (документар, шулай ук урынга чыгып) үткәрү вакыты 20 эш көненнән артмаска тиеш.

Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата планлы урынга чыгып тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен елына илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш.

Планлы урынга чыгып тикшерү үткәрүче ТР ЭТРМ вазифаи затларының нигезле тәкъдимнәре буенча катлаулы һәм (яки) озакка сузылган тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар үткәрү зарурилыгына бәйле искәрмә очракларда планлы урынга чыгып тикшерү үткәрү вакыты министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә 20 эш көненә генә, кече предприятиеләргә, микропредприятиеләргә карата – күп дигәндә 15 сәгатькә генә.

Эшчәнлеген Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә алып баручы юридик затка карата тикшерү (документар, шулай ук урынга чыгып) үткәрү срогы юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур подразделениесе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артмаска тиеш.

2.2.2. Планлы тикшерүләр күп дигәндә өч елга бер тапкыр үткәрелә.

**2.3. Тикшерүләр үткәрүгә нигезләр**

2.4.1. Планлы тикшерүләр ТР ЭТРМ тарафыннан эшләнелә торган еллык тикшерү планнары нигезендә хәл ителә.

ТР ЭТРМ планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 1 сентябренә кадәр планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнары проектларын (алга таба – Планнар) прокуратура органнары тапшыра.

Планлы тикшерүне Планга кертүгә түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) юридик затны, шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвен алу;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерү үткәрүнең тәгәлләнүе;

3) юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тиешле өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыруны башлап җибәрү турында тапшырылган белдерүнамә (әлеге белдерүнамәне тапшыруны таләп иткән эшләр башкару яки хезмәтләр күрсәтү очрагында) нигезендә эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрүгә өч ел узу.

Юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү турында ТР ЭТРМ боерыгы (әмернамәсе) Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында төбәк дәүләт экология контрольлеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентына № 4 кушымтасында китерелгән рәвеш нигезендә рәсмиләштерелә.

2.3.2. Планнан тыш тикшерү үткәрүгә түбәндәгеләр нигезләр булып тора:

1) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында элек бирелгән күрсәтмәне юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан үтәү вакыты чыгу;

2) ТР ЭТРМга түбәндәге фактлар турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат алу:

а) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), дәүләт иминлегенә зыян куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы килеп чыгу;

б) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), дәүләт иминлегенә зыян килү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

в) кулланучыларның хокукларын бозу (хокуклары санга сугылмаган гражданнарның мөрәҗәгать итү очрагында).

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм законнар үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында прокуратура органнарыннан алынган материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе белән чыгарылган министр боерыгы (әмернамәсе).

ТР ЭТРМга мөрәҗәгать иткән затны билгеләү мөмкинлеге бирмәгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук югарыда телгә алып үтелгән фактлар

турында мәгълүматлардан тормаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итә алмый.

ТР ЭТРМ юридик затлар, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә планнан тыш урынга чыгып тикшерү бу пунктның 2 пунктчасындагы “а” һәм “б” пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча үткәрелә.

ТР ЭТРМның юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гариза Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында төбәк дәүләт экология контрольлеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентына 5 кушымтасында китерелгән форма нигезендә рәсмиләштерелә.

**2.4. Дәүләт күзәтчелеген турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазифаи затлар**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.09.2011 ел, № 784 карары нигезендә билгеләнгән дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы ТР ЭТРМ вазифаи затлары исемлеге 2.2 таблицада китерелә.

2.2 таблица. – Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге.

| ТР ЭТРМда вазифаи зат вазифасы атамасы | Инспектор вазифасы атамасы |
| --- | --- |
| **Министр урынбасары (дәүләт экология күзәтчелеге мәсьәләләре буенча тикшереп торучы)** | **Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы;**<br><br>**Татарстан Республикасының җир асты биләмәләрен геологик өйрәнү, алардан рациональ файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча баш дәүләт инспекторы;**<br><br>**Татарстан Республикасының су объектларыннан файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча баш дәүләт инспекторы** |
| **Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы;**<br><br>**территориаль идарәләр башлыклары** | **Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы урынбасарлары;**<br><br>**Татарстан Республикасының җир асты биләмәләрен геологик өйрәнү, алардан рациональ файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча баш дәүләт инспекторы урынбасарлары;**<br><br>**су объектларыннан файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча баш дәүләт инспекторы урынбасарлары** |
| **Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы урынбасарлары;**<br><br>**территориаль идарәләр башлыклары урынбасарлары** | **Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча өлкән дәүләт инспекторлары;**<br><br>**Татарстан Республикасының җир асты биләмәләрен геологик өйрәнү, алардан рациональ файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча өлкән дәүләт инспекторлары;**<br><br>**Татарстан Республикасының су** |

| | |
|---|---|
| | **объектларыннан файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча өлкән дәүләт инспекторлары** |
| **Территориаль идарәләрнең махсус инспекцияләр башлыклары;**<br><br>**территориаль идарәләрнең махсус инспекция башлыклары урынбасарлары;**<br><br>**территориаль идарәләрнең махсус инспекцияләрендәге бүлекләрнең башлыклары;**<br><br>**территориаль идарәләрнең махсус инспекцияләрендәге бүлекләренең баш белгечләре;**<br><br>**территориаль идарәләрнең махсус инспекцияләрендәге бүлекләренең әйдәп баручы белгечләре;**<br><br>**территориаль идарәләрнең махсус инспекцияләрендәге бүлекләренең 1, 2 категория белгечләре;**<br><br>**территориаль идарәләрнең 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре;**<br><br>**территориаль идарәләрнең 1, 2, разрядлы белгечләре;**<br><br>**Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 2, 3 разрядлы өлкән белгечләре, баш белгечләре, әйдәп баручы белгечләре;** | **Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторлары;**<br><br>**Татарстан Республикасының җир асты биләмәләрен геологик өйрәнү, алардан рациональдь файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча дәүләт инспекторлары;**<br><br>**Татарстан Республикасының су объектларыннан файдалану һәм аларны саклауга күзәтчелек итү буенча дәүләт инспекторлары** |

| | |
|---|---|
| **Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 1 категория белгечләре** | |

**2.5. 294-ФЗ Федераль законны бозган өчен юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең җаваплылыгы**

Тикшерүләр үткәрелгәндә юридик затлар үз җитәкчеләренең, башка вазифаи затларының яки вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итәргә; шәхси эшмәкәрләр үзләре булырга тиеш яки мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрүгә җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең булуын тәэмин итәргә тиеш.

№ 294-ФЗ Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерү үткәрүгә нигезсез комачаулаган, тикшерүләр үткәрелүдән читләшкән һәм (яки) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында билгеләнгән срокта ТР ЭТРМ күрсәтмәләрен үтәмәгән юридик затлар, аларның җитәкчеләре, вазифаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшмәкәрләр, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

**2.6. ТР ЭТРМ, аның вазифаи затларының тикшерү үткәрүдәге җаваплылыгы**

ТР ЭТРМ, аның вазифаи затлары тикшерү үткәргәндә тиешле вазифаларны, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәл кылган (гамәл кылмаган) очракта Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

ТР ЭТРМ Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазифаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә язмача хәбәр җиткерергә тиеш.

**2.7. Дәүләт вазифасын үтәгәндә түләү алуга нигезләр һәм түләү алу тәртибе**

Дәүләт вазифасы бушлай башкарыла.

Дәүләт вазифасын үтәү тәртибе турында мәгълүмат бушлай бирелә.

## 3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр

Үтәлеше контрольдә тотыла торган, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларны билгеләүче норматив-хокукый актлар, шулай ук тикшерү вакытында юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан күрсәтелергә тиешле документлар исемлекләре 1.2 пунктта, шулай ук бу Регламентның 3 бүлегендә китерелә.

## 4. Тикшерү үткәрелгәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырыла торган документлар

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик, зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырыла торган документлар (күчермәләре) исемлекләре, шулай ук мондый документларның формаларын раслаучы норматив-хокукый актлар 1.2 пунктта, шулай ук бу Регламентның 3 бүлегендә китерелгән.

## 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШМӘКӘРЛӘРГӘ ҺӘМ ШӘХСИ ЗАТЛАРГА КУЕЛА ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР

Дәүләт күзәтчелеге объектларына карата куела торган, бу Регламентның 1.4 пунктында билгеләнгән мәҗбүри таләпләр исемлеге 1 таблицада китерелә.

| Җир асты биләмәләрен нән файдалану төрләре | Мәҗбүри таләпнең формулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт | Тикшерү барышында күрсәтелә торган документлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| Җирле әһәмияттәге җир биләмәләрен нән файдалану | 1. Хокук билгели торган документлар булу | РФ ГК, 214 ст. 2 өлеше, 607 ст;<br><br>РФ КоАП 7.3 статьясы (җирле әһәмияттәге җир биләмәләренең өлешләре), 23.22.1 статьясы;<br><br>РФ ЖК 42 статьясы;<br><br>“Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 7, 10, 11, 12, 19, 19.1, 23.2 статьялары;<br><br>“Җир асты биләмәләре турында” ТРЗ 21, 23, 24, 25, 26, 27, | Тикшерелә торган субъект турында гомуми белешмәләр;<br><br>Җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензия, җир асты биләмәләреннән файдалану турында лияцензия килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә карата кушымталар (җир асты биләмәләреннән лицензияле файдалану |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 29 статьялары”;<br><br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.10.2009 г. N 715 карарының 2.1 п. | төрләре буенча файдаланганда);<br><br>җир кишәрлегенә карата хокук билгели торган документ;<br><br>җирләрне сәнәгать җирләренә күчерү турында карар күчермәсе (әгәр дә элегрәк җирләр башка категориягә караган булса);<br><br>тауны читләтү акты, тауны читләтү мөһере белән топографик план;<br><br>җир кишәрлегенең кадастр планы;<br><br>техник проект |
| | 2. Җир кишәрлегеннән, җир асты биләмәләреннән файдалану хокукын үтәү (җир кишәрлегеннән, җир асты биләмәләреннән файдалану хокукын үзирекле бүтән затка бирү, | РФ КоАП 7.10 статьясы (җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләреннән файдалану хокукын үзирекле бүтән затка бирү өлешендә), 23.22.1 статьясы | җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензия;<br><br>җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җир кишәрлеген үзирекле алмаштыру гамәле булмау) | | |
| | 3. Җирле әһәмияттәге җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензияләрнең шартларын үтәү | РФ Хөкүмәтенең 12.05.2005 N 293 карары белән расланган Җир асты биләиәләрен геологик өйрәнүне, алардан рациональ файдалануны һәм саклауны дәүләт контролендә тоту турында нигезләмәнең 7 пункты;<br><br>“Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 22 статьясы;<br><br>РФ ЮС 15.07.1992 N3314-1 карары | Җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензия, җир асты биләмәләреннән файдалану турында лияцензия килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә карата кушымталар |
| | 3.1. Лицензиянең гамәлдәге вакытын саклау | “Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 10, 11 статьялары | Җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензия |
| | 3.2. Лицензия таләпләрен һәм шартларын үтәү: лицензия алган җир асты биләмәләреннән файдаланучы турында белешмәләр; | “Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 12 статьясы;<br><br>РФ КоАП 7.10 статьясы (җирле әһәмияттәге җир асты | Җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензия, җир асты биләмәләреннән файдалану турында лияцензия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җир асты биләмәләреннән файдалануга бәйле эшләрнең максатчан билгеләнеше турында белешмәләр;<br><br>файдалануга тапшырылучы җир асты кишәрлекләренең пространстволы чикләре (почмак нокталарының координаталары исемлеге белән);<br><br>җир асты биләмәләреннән файдалануга бәйле эшләрне алып бару өчен бүлеп бирелгән яки беренчел килештерелгән җир кишәрлегенең (акваториясенең) чикләре;<br><br>эшләрнең башлану вакытлары;<br><br>минерал чимал табуның килештерелгән дәрәҗәсе, табылган минерал чималга карата милекчелек | биләмәләреннән файдалану хокукын үзирекле бүтән затка бирү өлешендә), 23.22.1 статьясы;<br><br>РФ КоАП 8.5 статьясы (гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын үз эченә алучы җир асты биләмәләренең, җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренең, шулай ук файдалы казылмаларны табуга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү өчен файдаланыла торган җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренең торышы турында мәгълүматны әйтми калдыру яки бозып әйтү өлешендә), 23.22.1 статьясы;<br><br>РФ Хөкүмәтенең “Әйләнә-тирә | килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә карата кушымталар; геологик-разведка эшләрен үткәрүгә карата проект (геологик-разведка эшләрен алып барганда);<br><br>ИНН, устав;<br><br>гомумтаралган файдалы казылмаларны тапканда җир асты кишәрлекләреннән файдалануга һәм рекультивацияләүгә карата техник проект;<br><br>әйләнә-тирә мохит һәм табигый ресурслар торышы турында, әйләнә-тирә мохитне һәм табигый ресурсларны пычратучы чыганаклар яки әйләнә-тирә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хокукы;<br><br>тау эшләнмәләрен юк итү яки консервацияләүнең һәм җирләрне рекультивацияләүнең тәртибе һәм вакытлары;<br><br>гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка шартлар;<br><br>әйләнә-тирә мохит һәм табигый ресурслар торышы турында, әйләнә-тирә мохитне һәм табигый ресурсларны пычратучы чыганаклар яки әйләнә-тирә мохиткә һәм табигый ресурсларга булган башка төрле начар йогынты турында, радиация вәзгыяте турында, шулай ук җир, су объектлары һәм әйләнә-тирә мохитнең башка объектларының торышы турында мондый мәгълүматларны | мохитне саклау өлкәсендә дәүләт контрольлеген (дәүләт экология контролен) гамәлгә ашыру турында” 27.01.2009 N53 карары белән расланган Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт контрольлеген (дәүләт экология контролен) гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 9 пункты;<br><br>ТР ЭТРМ 29.05.2003 N491 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы предприятиеләренең һәм оешмаларының табигатьне саклау планнарын төзү буенча күрсәтмәләр;<br><br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 12.10.2009 N 715 карары | мохиткә һәм табигый ресурсларга булган башка төрле начар йогынты турында, радиация вәзгыяте турында, шулай ук җир, су объектлары һәм әйләнә-тирә мохитнең башка объектларының торышы турында мәгълүматлар;<br><br>Җир асты биләмәләрен өйрәнү, алардан файдалану һәм саклау өлкәсендә әйләнә-тирә мохитне саклау буенча программалар, планнар, чаралар;<br><br>җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау буенча чараларны үтәү турында хисаплар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җиткерергә бурычлы затлар тарафыннан тулы һәм дөрес мәгълүматны үз вакытында хәбәр итү;<br><br>әйләнә-тирә мохитне саклау буенча программаларны, планнарны һәм чараларны башкару | | |
| | 3.3. Гомум-таралган файдалы казылма ятмаларын разведкалауны һәм аларны табуны башкаручы оешмалар тарафыннан дәүләт хисапнамәсен геология мәгълүматы фондларына үз вәкаләтләре кысаларында тапшыруның билгеләнгән тәртибен үтәү | РФ Хөкүмәтенең 28.02.1996 N 215 карары белән расланган Гомум-таралган файдалы казылма ятмаларын разведкалауны һәм аларны табуны башкаручы оешмалар тарафыннан дәүләт хисапнамәсен геология мәгълүматының федераль һәм территориаль фондларына үз вәкаләтләре кысаларында тапшыруның билгеләнгән тәртибе;<br><br>РФ Статистика | Каты файдалы казылма запасларының торышын (үзгәрешен) федераль дәүләт статистика күзәтүе рәвешен (рәвеш 5-гр) һәм аңа карата аңлатма язуын җибәрү турында белешмәләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | буенча дәүләт комитетының “Россия ТРМ тарафыннан файдалы казылма запасларына, геология-разведка эшләренә һәм аларны финанслауга, судан файдалануга һәм әйләнә-тирә мохитне пычраткан өчен исәпләнгән түләүләргә статистик күзәтү оештыру өчен статистик чараларны раслау турында” 13.11.2000, № 110 карары | |
| | 4. Җир асты биләмәләрен геологик өйрәнү буенча, аларны үтәмәү разведкаланган файдалы казылма запасларын бәяләүнең төгәлсезлегенә китерергә мөмкин булган яки китергән кагыйдәләрне һәм таләпләрне яисә файдалы казылмаларны табу буенча | “Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 23 статьясының 2 пункты;<br><br>РФ КоАП 8.11 статьясы (җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен геологик өйрәнү буенча эшләр үткәрү өлешендә), 23.22.1 статьясы | Геология документлары;<br><br>җир асты кишәрлекләрен өйрәнүнең геология нәтиҗәләрен раслый торган документлар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | предприятиеләрне, шулай ук файдалы казылмаларны табуга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм файдалану өчен шартларны үтәмәү, җир биләмәләрен алга таба геологик өйрәнү һәм ятмаларын эшләү өчен кирәкле булган геология документларын, файдалы казылма һәм керн пробаларының дубликатларын югалту | | |
| “Җир асты биләмәләре турында” РФ Законының 19 һәм 19.1 статьялары нигезендә гомумтарал-ган файдалы казылмалар табу | 5. Үз территориясендә җир асты биләмәләреннән файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча вәкаләтләр кысаларында кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары таләпләрен үтәү | РФ Хөкүмәтенең 12.05.2005 N 293 карары белән расланган Җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүне, алардан файдалануны һәм саклауны дәүләт контролендә тоту турында нигезләмәнең 7 пункты | Җир асты биләмәләреннән файдаланучылар тарафыннан җир асты биләмәләреннән файдалануга һәм аларны саклауга бәйле булган барлык эш төрләре үткәрелгәндә мәҗбүри көчкә ия булган, билгеләнгән тәртиптә расланган Татарстан Республикасы норматив- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | хокукый актлары, стандартлары (нормалар һәм кагыйдәләр) |
| | 6. Дәүләт күзәтчелеген башкаручы органның (вазифаи затның) законнардагы бозуларны бетерү турында законлы күрсәтмәсен (карарын, йогынты актын, әмерен) вактында башкару | РФ КоАП 1,3 статьясының 5 өлеше, 28.3 статьясының 2 өлешендәге 30 пункты, 19.5 статьясының 1 өлеше, 19.6 статьясы;<br><br>РФ Хөкүмәтенең "Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт контрольлеген (дәүләт экология контролен) гамәлгә ашыру турында" 27.01.2009 N53 карары белән расланган Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт контрольлеген (дәүләт экология контролен) гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 9, 11 пунктлары | җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча элеккеге җикшерүләрнең нәтиҗәләренә бәйле документлар: элеккеге тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча актлар һәм күрсәтмәләр; административ хокук бозулар турында беркетмәләр (карарлар);<br><br>боерыклар һәм законнардагы бозуларны бетерү буенча чаралар планы;<br><br>законнардагы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | бозуларны бетерү буенча чараларны башкару турында хисаплар |

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЮРИДИК ЗАТҺӘМ ШӘХСИ ЭШМӘКӘР ТАПШЫРА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат һәм шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив-хокукый актлар 2 таблицада китерелде.

**2 таблица. Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат һәм шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге**

| Тикшерү үткәргәндә тапшырыла торган документ | Документ рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт |
|---|---|
| 1. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында белдерүнамә (Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган эшләр һәм хезмәтләр исемлеге нигезендә эшләр һәм хезмәтләр башкаруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен) | “Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26.12.2008, № 294-ФЗ Федераль законның 8 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында” 16.07.2009 № 584 карары |
| 2. Җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ | РФ ҖК 5 ст. |
| 3. Җир асты биләмәләреннән файдалануга карата лицензия, җир асты биләмәләреннән файдалану турында лияцензия килешүе, лицензия килешүенә өстәмәләр, лицензиягә карата кушымталар | “Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 11 ст, “Җир асты биләмәләре турында” ТРЗ 21 ст. |
| 4. Туны читләтү акты, тауны | “Җир асты биләмәләре турында” |

| | |
|---|---|
| читләтү мөһере белән топографик план | РФЗ 7 ст., РФ ТРМ 07.02.1998 г. № 56 боерыгы белән расланган “Файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен тау читләрен рәсмиләштерү буенча күрсәтмә” |
| 5. Җир кишәрлегенең кадастр планы, кадастр паспорты | РФ ЖК 31 ст. 5 п. |
| Җир асты кишәрлекләреннән файдалануга һәм рекультивацияләүгә карата техник проект;<br>геология-разведка эшләренә шартнамә | |
| 7. Соңгы ел өчен һәм узган елның узган чоры өчен файдалы казылмаларны табуга карата салым декларациясе (НДПИ) (айлар буенча декларацияләрнең күчермәләре) | РФ СК 334, 336, 345 статьялары |
| 8. Җир асты биләмәләреннән файдалану хокукына карата күләм коэффициентын (сипмә тыгызлыкны) һәм түләүләр хисаплауны коррект билгеләү максатлары өчен табыла торган чималны контроль үлчәү нәтиҗәләре (НДПИ) | РФ СК 339 ст. |
| 9. Ятма урынын эшләүне прокутлауга карата шартнамә | - |
| 10. Җир асты кишәрлекләрен геологик өйрәнүнең нәтиҗәләрен раслый торган документлар | - |
| 11. Тау эшләрен үстерүнең еллык планнары һәм аларны Ростехнадзор органнарында килештерү беркетмәләре | “Җир асты биләмәләре турында” РФЗ 22 ст. 2 өл. |

| | |
|---|---|
| 12. җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча элеккеге җикшерүләрнең нәтиҗәләренә бәйле документлар:<br>- элеккеге тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча актлар һәм күрсәтмәләр;<br>- боерыклар һәм законнардагы бозуларны бетерү буенча чаралар планы;<br><br>- законнардагы бозуларны бетерү буенча чараларны башкару турында | ТР ЭТРМ “Дәүләт экология контрольлеген үткәргәндә рәсмиләштерелә торган документларның рәвешләрен гамәлдәге законнарга туры китерү турында” 12.08.2009 № 870 боерыгы |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) БАШКАРУНЫҢ СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ БАШКАРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### 5.1. Планлы тикшерү үткәрүнең административ процедуралары

Дәүләт күзәтчелеге юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы (документар һәм урынга чыгып) һәм планнан тыш (документар һәм урынга чыгып) тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламент түбәндәге административ процедураларның үтәлешен күздә тота:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы документар тикшерү үткәрү;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү.

Дәүләт вазифасын үтәүнең блок-схемасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелә.

Дәүләт вазифасын үтәүне туктату Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

#### 5.1.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.1.1.1. Тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне еллык Планга кертү “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Регламентның 2.3.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә башкарыла.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы түбәндәге эш тәртипләре буенча гамәлгә ашырыла:

планлы документар тикшерүне үткәрүгә җаваплы вазифаи затларны билгеләү карарын кабул итү;

планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) формалаштыру;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә планлы документар тикшерү үткәрү турында хәбәр җиткерү;

планлы документар тикшерүне үткәрү;

үткәрелгән планлы документар тикшерүнең нәтиҗәләрен формалаштыру.

5.1.1.2. Тикшерүләр планы нигезендә ТР ЭТРМ структур бүлекчәләренең башлыклары:

ТР ЭТРМ вазифаи затлары арасыннан җаваплы башкаручыларны билгели, шул ук вакытта, әлеге Регламентның 2.4 п. нигезендә, тикшерүне үткәрүче вазифаи затның (алга таба – җаваплы башкаручы) юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү вәкаләтләренә ия булуы карарны кабул итүгә критерий булып тора;

кирәк булган очракта, тикшерелүче юридик зат, шәхси эшмәкәр белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт килешүләре мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затларның аффилирлы затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү вакыты: үткәреләчәк тикшерүне башлар алдыннан биш эш көне дәвамында яисә еллык Планны төзегәннән соң турыдан-туры.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.1.1.3. Җаваплы башкаручы:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү турында ТР ЭТРМ боерыгын (әмернамәсен), җаваплы башкаручыларга, ТР ЭТРМ Үзәк махсуслашкан аналитика контрольлеге инспекциясе белгечләренә юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) объектында (объектларында) күзәтчелек чараларын үткәрү өчен әлеге Регламентның 3 кушымтасы рәвешендә план-биремен әзерли;

әмернамә проектын министрга (министр урынбасарына) имзалау өчен юллый.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә үткәреләчәк тикшерү турында хәбәр итү вакытын (хәбәр итү вакыты хәбәр җиткерүнең ысулыннан чыгып билгеләнә) исәпкә алмыйча, тикшерүне үткәрә башлаганчы өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүне үткәрү турында министр (министрның урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык (әмернамә).

5.1.1.4. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәреләчәге турында тикшерүне үткәрү турында, әмернамә күчермәсен почта аша заказлы хат җибәрү юлы белән, яисә башка үтемле ысул (факсимиль элемтә, электрон почта аша, атап, кулга алу турында тамгасы белән) ярдәмендә хәбәр итә.

Үтәү вакыты: үткәреләчәк тикшерү башланыр алдыннан өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына юлланган тикшерүне үткәрү турындагы боерыкның (әмернамәнең) күчермәсе.

Үзен-үзе җайга салучы оешманың әгъзаларына планлы тикшерү үткәрелгәндә, җаваплы башкаручы үзен-үзе җайга салучы оешмага, тикшерү башланырга өч эш көне кала, аның вәкиленә үткәрелүче планлы тикшерүдә катнашу яисә булу мөмкинлеген тудыру максатларында, белдерүнамә юллый.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр ун эш көне дәвамында тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмернамә) күчермәләрендә күрсәтелгән документларны мөһер (булган очракта) һәм шулай ук шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик затның җитәкчесенең, башка вәкаләтле затының имзасы белән рәсмиләштерелгән күчермәләре рәвешендә ТР ЭТРМ юлларга бурычлы.

Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, ТР ЭТРМ тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр соратып алу гаризасында күрсәтелгән әлеге документларны, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә, электрон документлар рәвешендә дә юллый ала.

5.1.1.5. Җаваплы башкаручы ТР ЭТРМ карамагындагы документларның мәгълүматлары һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләр нигезендә:

мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

документлардагы мәгълүматларга, юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килүе предметына карата бәяләмә үткәрә;

юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мәҗбүри таләпләрне үтәве турында бәяләмә формалаштыра.

Әгәр документлардагы мәгълүматларның дөреслеге шик тудырса, яисә әлеге мәгълүматлар мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, әгәр дә ТР ЭТРМ тапшырылган документлардагы мәгълүматларның хаталы һәм (яисә) каршылыклы, туры килми торган булуы ачыкланса, җаваплы башкаручы:

юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына ун эш көне дәвамында язма рәвештә кирәкле аңлатмаларны яисә карау өчен кирәкле булган башка документларны тапшыруны таләп итеп, һәм белешмәләрне бәяләүнең

нәтиҗәләре турында мәгълүматларны һәм нигезле соратып алу гаризасын үз эченә алган хат әзерли;

хатны, имзалатып кулга тапшыру яисә кулга алу турында тамгасын куюю хәбәрен җибәрү юлы белән, почта аша заказлы хат итеп юллый.

Үтәү вакыты: үткәреләчәк тикшерү башланыр алдыннан биш эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына юлланган, карап тикшерү өчен бүтән төрле документларны таләп итүле (нигезле соратып алу гаризалы) хат.

5.1.1.6. Урынга чыгып тикшерү шушы Регламентның 5.1.2 пунктында китерелгән тәртиптә башкарыла.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны һәм (яки) документларны алган мизгелдән башлап өч эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларында булган белешмәләрне бәяләү турында бәяләмә яки урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) проекты.

5.1.1.7. Җаваплы башкаручы юридик затның, шәхси эшмәкәрнең мәҗбүри таләпләрне үтәве турында бәяләмә нигезендә юридик затны, шәхси эшмәкәрне ТР ЭТРМ тарафыннан тикшерү турында ике нөсхәдә тикшерү акты төзи.

Мәҗбүри таләпләрне контрольдә тоту чаралары нәтиҗәсендә бозулар ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны үтәүгә юнәлдерелгән чираттагы чараларны (ачыкланган бозулар нәтиҗәсендәге зыянны каплау) гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган барлык бозуларны терки;

ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерү һәм (яисә) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүне, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләт яисә муниципаль милеккә булган зарарны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны булдырмый калу буенча чараларны, һәм шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны үткәрү вакытларын күрсәтеп, мәҗбүри үтәлергә тиешле, тикшерү актына кушымта булучы (һәр бозу буенча аерым күрсәтмә) күрсәтмәләр (күрсәтмәнең формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында күрсәтелгән) бирә, һәм әлеге күрсәтмәләрнең билгеләнгән вакытларда әлеге Регламентта каралган тәртиптә үтәлешен контрольдә тота;

РФ КоАП 7.3 ст., 7.10 ст., 8.4 ст., 8.9 ст., 8.10 ст. 1 өл., 8.11 ст., 19.4 ст. 1 өл., 19.4 ст. 1 өл., 19.5 ст. 1 өл., 19.5 ст. 1 өл., 19.6 ст., 19.7 ст., 19.33 ст. каралган административ хокук бозу күренешләре ачыкланганда, законда билгеләнүче тәртиптә каралучы административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Әгәр дә контроль буенча чаралар барышында контрольлек чаралары үткәрелүче хуҗалык яисә башка эшчәнлек объектының законнардагы

таләпләрнең бозылуына бәйле булуы ачыкланса, бу бозуларны ачыклау, булдырмый калу һәм бетерү мәсьәләләре ТР ЭТРМ вәкаләтенә карамаса, ТР ЭТРМ мондый бозулар турындагы мәгълүматларны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең яисә Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына (Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча ТР территориаль агентлыгы (“Татарнедра”), Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең ТР Идарәсе, Экология һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең ТР Технология һәм экология күзәтчелеге идарәсе (Ростехнадзор), Ветеринар һәм фитосанитар күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең ТР Идарәсе, РФ ТРМ Түбән Идел су бассейны идарәсенең ТР су ресурслары бүлеге, Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсе, “Средволгаводхоз” су хуҗалыгы буенча ФДИ, ТР Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы, ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе) юлларга бурычлы.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә беркетә, икенчесен, тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту турында имза куйдырып, юридик зат җитәкчесенә, башка вазифаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә (кушымталары белән берлектә) тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле урында булмаган очракта, һәм шулай ук тикшерелүче зат тикшерү акты белән танышу яисә танышудан баш тарту буенча имза куюдан баш тарткан очракта, акт кулга тапшыру хәбәрнамәсе белән почта аша, заказлы хат итеп җибәрелә, хәбәрнамә тикшерү актының ТР ЭТРМ саклanучы эшкә теркәлүче нөсхәсе беркетелә.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын тапшыру: тикшерүне тәмамлаганнан соң турыдан-туры;

- тикшерү актын заказлы хат итеп җибәрү: контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның беренчесе юридик затка, шәхси эшмәкәргә тапшырылган (юлланган), икенчесе эшкә беркетелгән.

5.1.1.8. Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзаларының мәҗбүри таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үзен-үзе җайга салучы оешмага ачыкланган бозулар турында үткәрелгән тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында белдерүнамә юллый.

5.1.1.9. “Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планлы документар тикшерү” административ процедурасын үтәүнең нәтиҗәсе электрон рәвештә ТР ЭТРМ рәсми сайтында теркәлә.

### 5.1.2. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.1.2.1. Тиешле юридик затны, шәхси эшмәкәрне ТР ЭТРМ еллык Планына кертү “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора, ягъни документар тикшерүдә түбәндәгеләр мөмкин булмаса:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең ТР ЭТРМ карамагындагы документларында булган мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә ышану;

2) юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген контрольдә тоту буенча тиешле чараларны үткәрмичә мәҗбүри таләпләргә турын килүен бәяләү.

Юридик затны, шәхси эшмәкәрне планлы тикшерүне планлы тикшерүләрне үткәрүнең еллык Планына кертү әлеге Регламентның 2.3.1 пунктларында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасы әлеге Регламентның 5.1.1.1 пунктында күрсәтелгән аналогик административ гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.1.2.2. Җаваплы затны, экспертларны билгеләү, юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) әзерләү, юридик затка, шәхси эшмәкәргә үткәреләчәк тикшерү турында хәбәр итү әлеге Регламентның 5.1.1.2-5.1.1.4 пунктларында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

5.1.2.3. Җаваплы башкаручы, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең объектына килгәннән соң, тикшерүне түбәндәгеләрдән башлый:

- хезмәт таныклыкларын күрсәтүдән;

- юридик зат җитәкчесен яисә башка вазифаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен министрның (министр урынбасарының) урынга чыгып тикшерүне үткәрү турындагы боерыгы (әмернамәсе) белән мәҗбүри таныштырудан;

- юридик затның башка вазифаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен урынга чыгып тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре, һәм шулай ук максатлары, бурычлары, урынга чыгып тикшерүнең нигезләре, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып үткәрелүче тикшерүгә җәлеп ителүче экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең составы, аны үткәрүнең вакытлары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырудан.

Җаваплы башкаручылар, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре күзәтчелек буенча чираттагы чараларны үткәрә:

оешу-хокукый рәвешенең һәм милекчелек рәвешенең нинди булуына карамастан, федераль дәүләт экология күзәтчелегендәге объектлардан гайре, хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларын тикшерә, дәүләт күзәтчелеген башкаруга кирәкле булган документлар һәм башка материаллар белән танышу максатларында, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә бара;

җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау, чистарткыч корылмаларның һәм башка төрле зарарсызландыручы җайланмаларның, контрольлек чараларының эшләве, шулай ук җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау буенча планнарны һәм чараларны үтәү өлкәсендә нормативларның, дәүләт стандартларының һәм башка төрле норматив документларның үтәлешен тикшерә;

җитештерү һәм башка объектларны урнаштырганда, файдаланганда һәм файдаланудан чыгарганда җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендәге таләпләрнең, нормаларның һәм кагыйдәләрнең үтәлешен тикшерә;

Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт күзәтчелегенә тиешле объектларда хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек башкарганда дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән таләпләр үтәлешен тикшерү һәм аны үткәрү турында тәкъдимнәр кертү;

юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә, аларны бетерү вакытларын күрсәтеп, бозуларны бетерү турында һәм (яисә) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләргә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның милкенә, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә зарарны булдырмый калу, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү буенча чаралар, һәм шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны үткәрү турында таләпләр куя һәм күрсәтмәләр бирә (күрсәтмәнең рәвеше әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелә) (күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора һәм һәр бозу очрагы буенча аерым төзелә);

мәҗбүри таләпләрнең бозылышы буенча җаваплылык йөкләнгән юридик зат эшчеләреннән, шәхси эшмәкәр эшчеләреннән аңлатмалар соратып ала;

җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендә законнар бозылуга юл куйган затларны билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тарту.

ТР ЭТРМ аналитика күзәтчелегенең махсуслашкан инспекциясе белгечләре чираттагы чараларны үткәрә:

- продукция үрнәкләрен, тикшерү пробаларын ала.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты – егерме эш көненнән дә артык түгел.

5.1.2.4. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.1.1.7 пунктында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлергә мөмкин:

- җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләре объектларыннан һәм җитештерү тирәлеге объектларыннан продукция үрнәкләрен, тикшерү пробаларын алу беркетмәләре;

- үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре;

- тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган башка документлар яисә аларның күчермәләре.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләр, сынаулар, махсус эзләнүләр, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң, өч эш көненнән артмаган чорда, юридик затка, шәхси эшмәкәргә юллана.

Җаваплы зат үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының исеме, үткәрелгән тикшерүнең башлану һәм тәмамлану көннәре, аны үткәрүнең вакыты, хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм тикшерүнең предметы, ачыкланган хокук бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы мәгълүматларны үз эченә алган язу терки, һәм шулай ук тикшерүне үткәрүче вазифаи затның яисә вазифаи затларның фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен һәм аның яисә аларның имзаларын, вазифаларын күрсәтә.

5.1.2.5. Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзаларының мәҗбүри таләпләрне бозулары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы үзен-үзе җайга салучы оешмага ачыкланган бозулар турында үткәрелгән тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә белдерүнамә җибәрә.

5.1.2.6. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

## 5.2. Планнан тыш тикшерүләр үткәрүнең административ процедуралары

Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата дәүләт күзәтчелеген башкару максатларында планнан тыш тикшерүләр үткәрү түбәндәге административ процедураларны күз уңында тота:

юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү.

### 5.2.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.2.1.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.3.2 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы шушы Регламентның 5.1.1.1 пунктында күрсәтелгән тәртиптә башкарыла.

5.2.1.2. Министр (министр урынбасары) планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.3.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр килеп туганда:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү буенча җаваплы башкаручыларны билгели;

кирәк булган очракта, тикшерелүче юридик зат, шәхси эшмәкәр белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелүче затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп итә.

Үтәү вакыты: планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез барлыкка килгән көннән алып бер эш көне дәвамында.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән җаваплы башкаручы.

5.2.1.3. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы министр (министр урынбасары) боерыгын (әмернамәсен) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.1.3 пункты нигезендә юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә җаваплы затны билгеләү көнендә башкарыла.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш документар тикшерү үткәрүгә җаваплы затны билгеләү көнендә.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерүне үткәрү турында министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык (әмернамә).

5.2.1.4. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү үткәрү турында хәбәр итү шушы Регламентның 5.1.1.4 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

5.2.1.5. Җаваплы затның юридик затның, шәхси эшмәкәрнең документларында булган мәгълүматларны бәяләү, юридик зат, шәхси эшмәкәр адресына хат (нигезле соратып алу гаризасы) әзерләү, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең тапшырылган документларындагы кисәтүләр буенча аңлатмаларын карау буенча эш-гамәлләре әлеге Регламентның 5.1.1.5, 5.1.1.6 пунктлары нигезендә башкарыла.

5.2.1.6. Тикшерү актын төзү шушы Регламентның 5.1.1.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Элегрәк ачыкланган закон бозулар буенча бирелгән күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә, ТР ЭТРМ законлы күрсәтмәсенең вакытында үтәлмәве, һәм, шулай ук, РФ КоАП 19.5, 19.6 статьяларында каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрелмәү административ хокук бозулар буенча эш кузгатуга нигез булып тора

Яңадан ачыкланган бозулар, һәм шулай ук системалы характер алган бозу очраклары мәҗбүри тәртиптә теркәлә.

5.2.1.7. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

### 5.2.2. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.2.2.1. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.3.2 пунктында каралган нигезләр сәбәп булып тора.

“Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасы шушы Регламентның 5.1.1.1 пунктында күрсәтелгән гамәлләр тәртибе нигезендә башкарыла.

5.2.2.2. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен җаваплы затларны билгеләү, экспертларны җәлеп итү әлеге Регламентның 5.2.1.2 пункты нигезендә башкарыла.

5.2.2.3. Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.1.3 пункты нигезендә башкарыла.

Үтәү вакыты: Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен җаваплы затларны билгеләгән көнне.

Эшнең нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) тарафыннан имза салынган боерык (әмернамә).

5.2.2.4. Урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрүгә әлеге Регламентның 2.3.2 пунктының 2 пунктчасындагы “а”, “б” пункт өлешләрендә күрсәтелгән нигезләр нигез булып торса, җаваплы башкаручы:

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата урынга чыгып үткәреләчәк планнан тыш тикшерүнең юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек башкару урыны буенча прокуратура органнары белән килештерү турында гариза әзерли һәм аны министрдан (министр урынбасарыннан) имзалата;

юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата үткәреләчәк урынга чыгып планнан тыш тикшерүнең юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге урыны буенча прокуратура органнары белән килештерү турында гаризаны атап тапшыра, почта аша заказлы хат итеп кулга тапшыру хәбәрнамәсе белән яисә электрон сан имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә юллый. Гаризага министрның (министр урынбасарының) урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыгының (әмернамәсенең) күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган, мәгълүматларны үз эченә алучы документлар теркәлә.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерык (әмернамә) имзаланган көнне.

Эшнең нәтиҗәсе: урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органына юлланган гариза.

Кичекмәстән үткәрелергә тиешле чараларга керешү кирәк булу сәбәпле ТР ЭТРМ, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында гаризаны,

урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы боерыкның (әмернамәнең) һәм аны үткәрүгә нигез булучы мәгълүматларны үз эченә алучы документларның күчермәләрен егерме дүрт сәгать эчендә юллау юлы белән, прокуратура органнарына хәбәр итеп, кичекмәстән урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрүгә керешергә хокуклы.

5.2.2.5. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшмәкәргә (әлеге Регламентның 2.3.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелүче урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән гайре) урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында аны үткәрә башлаганчы егерме дүрт сәгать алдан теләсә нинди үтемле ысул белән хәбәр итә.

Әгәр дә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салынган булса яисә салынса, һәм шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкса яисә килеп чыгарга мөмкин булса, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүнең башлануы турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзаларына карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәргәндә, җаваплы башкаручы, урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерүдә аның вәкилләрен катнаштыру һәм булдыруны тәэмин итү максатларында, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында үзен-үзе көйләүче оешмага хәбәр итә.

5.2.2.6. Урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү әлеге Регламентның 5.1.2.3 пункты нигезендә башкарыла.

Элегрәк ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә ТР ЭТРМ тарафыннан бирелгән законлы күрсәтмәнең билгеләнгән вакытка үтәлмәве, һәм шулай ук РФ КоАП 19.5, 19.6 статьяларында каралган административ хокук бозуларга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чараларның күрелмәве административ хокук бозулар буенча эш кузгатуга нигез булып тора.

Яңадан ачыкланган бозулар, һәм шулай ук системалы характерга ия булган бозу очраклары мәҗбүри тәртиптә теркәлә.

5.2.2.1. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.1.2.4 пункты нигезендә башкарыла.

Әгәр дә урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү прокуратура органы белән килештерелеп башкарылган булса, тикшерү актының күчермәсе, тикшерү актын төзү көненнән алып биш эш көне дәвамында прокуратура органына юллана.

5.2.2.8. Үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзалары тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы ачыкланган бозулар турында урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне дәвамында үзен-үзе көйләүче оешмага хәбәр итә.

5.2.2.9. “Юридик затка, шәхси эшмәкәргә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәүнең нәтиҗәсе ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

### 5.3. Административ хокук бозу турында эшләрне карап тикшерү

5.3.1. Административ хокук бозулар турындагы эш аны кылу урыны буенча карап тикшерелә. Административ хокук бозу турында эш аңа карата алып барыла торган затның үтенечнамәсе буенча эш әлеге затның яшәү урыны буенча карап тикшерелергә мөмкин.

Аның буенча административ тикшерү үткәрелгән административ хокук бозу турындагы эш административ тикшерүне үткәрүче органның урнашкан урыны буенча карап тикшерелә.

5.3.2. Административ хокук бозу турындагы эшне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы яки аның урынбасары түбәндәге карарны чыгара:

1) административ җәза билгеләү турында;

2) административ хокук бозу эшен туктату турында.

Административ җәза билгеләү турында карар затны хокук бозуда гаепле дип таныган очракта чыгарыла.

Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы яки аның урынбасары түбәндәге шартларның берсе генә булса да административ хокук бозу эшен туктату турында карар чыгара:

1) административ хокук бозуның вакыйгасы булмау;

2) зат бик зур зарурлык булуга бәйле гамәл кылса;

3) амнистия акты басылып чыгу, әгәр дә мондый акт административ җәза куллануны юкка чыгарса;

4) административ җаваплылыкны билгеләгән законны гамәлдән чыгару;

5) административ җаваплылыкка тарту буенча дәгъва вакыты узу;

6) аңа карата административ хокук бозу эше буенча эш алып барыла торган зат тарафыннан бер үк очрак буенча хокукка каршы гамәлләр кылынганда (гамәлләр кылынмаганда) яисә административ хокук бозу турында эшне туктату турында карар, яки җинаять эшен кузгату турында карар булганда;

7) аңа карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган физик затның вафаты.

5.3.3. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карарда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) карар чыгарган затның вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) эшне карап тикшерү датасы һәм урыны;

3) аңа карата эш карап тикшерелгән зат турында белешмәләр;

4) эшне карап тикшергәндә билгеләнгән шартлар;

5) Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының административ хокук бозган өчен административ җаваплылык карый торган статьясы яки эш буенча эш барышын туктату нигезләре;

6) эш буенча дәлилле карар;

7) карарны шикаять кылуның вакыты һәм тәртибе;

8) штраф алучы турында административ штраф суммаларын күчерү өчен исәп-хисап документларын тутыру өчен кирәкле булган мәгълүмат.

5.3.4. Административ хокук бозу турында эш буенча карар административ хокук бозу эшен карап тикшерүче Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы яки аның урынбасары тарафыннан имзалана һәм аны чыгарган территориаль идарә яки ТР ЭТРМ мөһере белән таныклана.

5.3.5. Административ хокук бозу турында эш буенча карар Татарстан Республикасының табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторы яки аның урынбасары тарафыннан эшне карап тикшерүне тәмамлагач ук кичекмәстән игълан ителә.

Административ хокук бозу турында эш буенча карар эш башкару өчен җаваплы булган үзәк аппаратның структур бүлекчәләрендәге яки ТР ЭТРМ территориаль идарәләрендәге вазифаи затлар тарафыннан тиешле карарны имзалаган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлә. Рәсмиләштерелгән һәм кулга тапшыру өчен әзерләнгән административ хокук бозу турында эш буенча карарның төп нөсхәсеннән архивта саклау өчен күчермә алына.

5.3.6. Административ хокук бозу турында эш буенча карарның төп нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә яки аның вәкиленә (ышанычнамә буенча) тапшыру шәхсән кулга биреп яки почта аша (кулга тапшыру турында белдерүнамә белән) җибәреп башкарыла.

5.3.7. Административ хокук бозу турында эш буенча карарның икенче нөсхәсе эш барышы өчен җаваплы булган үзәк аппаратның структур бүлекчәсендә яки ТР ЭТРМ территориаль идарәсендә саклана.

5.3.8. Административ хокук бозуның сәбәпләрен һәм аны кылуга китергән шартларны ачыклаган очракта, административ хокук бозу турында эшне карап тикшерүче вазифаи зат күрсәтелгән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү турында йогынты акты чыгара.

Йогынты акты аларга карата чыгарылган шәхси эшмәкәргә яки юридик затның законлы вәкиленә административ җаваплылыкка тарту турындагы карар белән бер үк вакытта җибәрелә.

### 5.4. Җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендәге законнарның таләпләре бозылуларны бетерүне контрольдә тоту

5.4.1. Җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендәге законнарның таләпләре бозылуны бетерү турындагы һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә

мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә, физик затларның һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яки муниципаль мөлкәткә зыян салынуны туктату, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны кисәтү, шулай ук федераль законнарда каралган башка чаралар турындагы күрсәтмәдә билгеләнгән җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендә законнарның таләпләре бозылуны бетерү вакыты узган мизгелдән башлап унбиш календарь көне дәвамында күрсәтелгән күрсәтмәне биргән җаваплы башкаручы элегрәк ачыкланган бозуның бетерелүенә карата тикшерү үткәрә.

5.4.2. Җибәрелгән бозуны бетергән очракта күрсәтмә биргән җаваплы башкаручы, шушы Регламентның 5.1.2.4 пунктына таянып, җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендәге законнарның таләпләре бозылуны бетерүне раслый торган документларны теркәп, җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшерү акты төзи.

5.4.3. Җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендәге законнарның таләпләре бозылуны бетермәгән очракта, күрсәтмәне биргән җаваплы башкаручы, акт белән бер үк вакытта РФ КоАП 19.5 статьясының 1 өлешендә каралган хокук бозу өчен административ хокук бозу турында беркетмә төзи һәм административ эш составында, билгеләнгән тәртиптә, аны төзегән мизгелдән башлап өч тәүлек дәвамында карап тикшерү өчен судка (җәмәгать судына) җибәрә, шул ук вакытта күрсәтмә контрольлектән алына. Табигать саклау законнарының кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә, физик затларның һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яки муниципаль мөлкәткә зыян салыну, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычына бәйле таләпләре бозылуны бетерү буенча күрсәтмәне үтәмәү турындагы мәгълүмат билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнарына җиткерелә.

## 6. ДӘҮЛӘТ ВАЗИФАСЫ ҮТӘЛЕШЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

6.1. ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан аларның хезмәт йөкләмәләре үтәлүен контрольдә тота, тикшерүләрне үткәргәндә вазифаи затлар тарафыннан вәкаләтләренең тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшеренүләрен алып бара һәм, Россия Федерациясе законнары нигезендә, мондый вазифаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тоту министр тарафыннан башкарыла.

6.3. Әлеге Регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеген башкару буенча эшләрнең вакытлары, эзлеклелеге үтәлешен, ТР ЭТРМ вазифаи затлары тарафыннан карарларның кабул ителүен агымдагы контрольдә тоту министрның урынбасары һәм ТР ЭТРМның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

6.4. Дәүләт вазифасының үтәлешен, әлеге контрольнең тәртибе һәм эзлеклелеге саклануны агымдагы контрольдә тотуга вәкаләтләнгән ТР ЭТРМ хезмәткәрләренең исемлеге ТР ЭТРМ актлары белән билгеләнә. ТР ЭТРМ хезмәткәрләренең агымдагы контроль буенча вәкаләтләре ТР ЭТРМ структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазифаи күрсәтмәләрендә билгеләнә.

ТР ЭТРМ тарафыннан үтәлүче дәүләт вазифасының тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне, тикшерелүче затларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерүне, кызыксынучы затларның ТР ЭТРМ вазифаи затларының эшенә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләреннән торучы мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карарлар кабул итү һәм аларга җавап әзерләүне үз эчен ала.

Тикшерүләр министрның (министр урынбасарының) әмернамәсе нигезендә үткәрелә. Тикшерүләрнең нәтиҗәләре дәүләт вазифасын башкарганда кимчелекләрнең булмавы яисә ачыкланган кимчелекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлгән акт рәвешендә формалаштырыла.

ГАРАНТ:

Пунктларның нумерациясе чыганак нигезендә китерелә

6.6. Дәүләт вазифасы үтәлешенең тулылыгын һәм сыйфатлы булуын планлы тикшерүләр агымдагы елга билгеләнгән ТР ЭТРМ еллык эшләр планы нигезендә башкарыла. Планлы тикшерүләр әлеге планга дәүләт вазифасын башкару аның вәкаләтенә караган министр урынбасары тарафыннан кертелә.

6.7. Дәүләт вазифасы үтәлешенең тулылыгына һәм сыйфатлы булу-булмавына карата үткәрелүче планнан тыш тикшерүләр ТР ЭТРМ вазифаи затларының дәүләт вазифасын үтәү барышында кабул ителгән яисә башкарылган карарларына яисә эшенә (гамәл кылмавына) карата гражданнардан алынган шикаятьләр (ризасызлыклар) нигезендә башкарыла.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә дәүләт вазифасын башкару барышында Министрлыкның вазифаи затлары тарафыннан бозулар җибәрелгәнлеге ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясенең законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә иҗтимагый контроль (иҗтимагый экология контроле) уңайлы әйләнә-тирә мохиткә һәркемнең хокукларын гамәлгә ашыру һәм атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге законнарның бозылуын булдырмый калу максатларында башкарыла.

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә иҗтимагый контроль (иҗтимагый экология контроле) иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерцияле

булмаган башка оешмалар тарафыннан аларның уставлары нигезендә, һәм шулай ук гражданнар тарафыннан законнарга нигезләнеп башкарыла.

Җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрен саклау өлкәсендә иҗтимагый контрольлек (иҗтимагый экология контроленең) Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиешле.

## 7. ДӘҮЛӘТ ВАЗИФАСЫН ҮТӘҮЧЕ ОРГАННЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗИФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫН ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕН (ГАМӘЛ КЫЛМАУЛАРЫН) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ КЫЛУ ТӘРТИБЕ

7.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, башка кызыксынучан затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) ТР ЭТРМ дәүләт вазифасын башкару барышында аның вазифаи затлары тарафыннан тикшерүне үткәрү барышында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән гамәлләрен (гамәл кылмауларын) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылучы) карарларын, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылырга хокуклы.

7.2. ТР ЭТРМ, аның вазифаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылуның предметы булып ТР ЭТРМ вазифаи затларының, аның территориаль идарәләренең дәүләт вазифасын үтәү барышында кабул иткән яисә башкарган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) тора.

7.3. Министрлыкка яисә вазифаи затка аларның компетенциясенә бәйле рәвештә кергән шикаять мәҗбүри каралырга тиешле.

Судка кадәрге (судтан тыш) каралырга тиешле шикаятьне караудан баш тартуга яисә карауны туктатып торуга нигезләр каралмаган.

7.4. Шикаятькә җавап түбәндәге очракларда бирелми:

- әгәр дә язма шикаятьтә шикаятьне юллаучы гаризачының фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә (әгәр дә әлеге шикаятьтә әзерләнеп ятучы, башкарылучы яисә хокукка каршы хәлләрнең башкарылуы турында, һәм шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять компетенциясенә караган дәүләт органына юлланырга тиеш);

- шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы тәгъбирләр кулланылса, ТР ЭТРМ вазифаи затының, һәм шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм милкенә куркыныч белән янаулар булса (ТР ЭТРМ вазифаи заты шикаятьне юллаучы гаризачыга хокуклары белән исәпләшмәүнең мөмкин түгеллеге хакында хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр дә язма шикаятьнең тексты укылышлы булмаса (әлеге шикаять шулай ук, аларның компетенциясе кысаларында, дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә вазифаи зат каравына җибәрелми), бу хакта шикаятьне теркәгән көннән җиде көн дәвамында шикаятьне юллаучы гаризачыга хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), почта адресы аңлаешлы булса;

- әгәр дә гаризачының шикаятендә аңа инде элегрәк җибәрелгән шикаятьләре нигезендә күп тапкырлар язмача җавап бирелгән сорау каралса һәм, шул ук вакытта, шикаятьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәсә (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә шул ук вазифаи затка җибәрелгән очракта (шикаятьне юллаучы гаризачыга ике арадагы язышуларны туктату карары турында хәбәр ителә);

- әгәр дә шикаятьтә куелган сорауга дәүләт яисә федераль закон белән саклanучы башка серне тәшкил итүче мәгълүматларны фаш итүдән гайре җавап биреп булмаса (шикаятьне юллаучы гаризачыга әлеге мәгълүматларны фаш итү мөмкин булмау сәбәпле, анда куелган сорауга җавап биреп булмау мөмкинлеге турында хәбәр ителә).

Суд карарына карата шикаять, теркәлү узганнан соң җиде көн эчендә, әлеге суд карарын шикаять кылу тәртибе аңлатылып, гаризачыга кире кайтарыла.

7.5. Гаризачының шәхси үзеннән (гаризачының вәкаләтле вәкиленнән) яисә почта аша җибәрелгән хат, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән Министрлыкның рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, электрон документ рәвешендә ТР ЭТРМ кергән шикаять ТР ЭТРМ, аның вазифаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылуны башлауга нигез булып тора.

7.6. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр шикаятьне дәлилләү һәм карау өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алуга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр ТР ЭТРМ адресына язмача формада тиешле соратып алу гаризасын юлларга тиеш. Министр (министр урынбасары), җаваплы башкаручылар соралучы мәгълүматларны һәм документларны гаризаны теркәгән көннән 30 көн эчендә бирергә тиешләр.

7.7. ТР ЭТРМ вазифаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять министрга юлланырга мөмкин. ТР ЭТРМ һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына карата шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланырга мөмкин.

7.8. ТР ЭТРМ яисә ТР ЭТРМ вазифаи затына кергән шикаять, аларның компетенциясе нигезендә, аның теркәлү көненнән 30 календарь көне дәвамында карала.

Искәрмәле очракларда, вазифаи яисә аңа вәкаләтле булган зат шикаятьне карау вакытын, шикаятьне юллаучы гаризачыга аның карау

вакытын озынайту турында хәбәр итеп, 30 календарь көненнән артмаган вакытка озынайта ала.

7.9. Судка кадәрге (судтан тыш) шикаять кылуның нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәүләт вазифасын башкару барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауларына) һәм кабул ителгән карарларга карата бирелгән судка кадәрге (судтант тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

– хезмәт тикшерүе барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) вазифаи йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәве очраклары ачыкланган очракта, аңа карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

– хокуклары һәм (яисә) законлы ихтыяҗлары бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаеплеләргә карата күрелгән чаралар турында, мондый чараларны күрү көненнән ун көн дәвамында язмача формада хәбәр ителә;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә мондый карарның нигезләрен күрсәтеп, язма формада хәбәр итү юлы белән, дәүләт вазифасын башкару барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм кабул ителгән (кабул ителүче) карарларга карата судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермәү.

7.10. ТР ЭТРМ кергән шикаятькә җавап гаризачыга әлеге Регламентның 7.9 п. каралган чараларны күргән көннән 10 көн дәвамында җибәрелә.

ТР ЭТРМ яисә вазифаи затка электрон документ формасында кергән шикаятькә җавап электрон документ формасында, шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы яисә шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы аша язмача формада җибәрелә.

**Татарстан Республикасы Экология**
**һәм табигый ресурслар министрлыгында**
**җирле әһәмияттәге җир асты**
**кишәрлекләренә карата җир асты**
**биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан**
**рациональ файдалануга һәм аларны**
**саклауга карата төбәк дәүләт**
**күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча**
**дәүләт вазифасын үтәүнең административ**
**регламентына карата 1 кушымта**
**(үрнәк рәвеше)**

## Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә (рәвеше)

| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫ | Герб Республики Татарстан | МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|---|

(дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органының яисә аның территориаль органының исеме)

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Почта адресы: (дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органы).; тел. (Дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органы).

________________________ «__» ________ 20__ ел.
(Актны төзү урыны) (актны төзү көне)

______________________
(актны төзү вакыты)

ТИКШЕРҮЛӘР НӘТИҖӘСЕНДӘ АЧЫКЛАНГАН
ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ ЗАКОННАРЫН БОЗУЛАРНЫ БЕТЕРҮ ТУРЫНДА
№ ______ КҮРСӘТМӘ

«__» _________ 20 ел. _____________________ ш.

Россия Федерациясенең табигатьне саклау законнарының таләпләрен үтәүне тикшерү буенча 20__ елның «__» _________. № ___ актына нигезләнеп, мин, ТР табигатьне саклау буенча дәүләт инспекторы

___________________________________________________________________________
(ТР ЭТРМ яисә аның территориаль органының вазифаи затының Ф.И.А.,

___________________________________________________________________________
вазифасы, хезмәт таныклыгы номеры,кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ

___________________________________________________________________________
(күрсәтмә бирелүче физик яисә юридик затның исеме)

| № п/п | Табигатьне саклау законнарының ачыкланган бозулары <**> | Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең эчтәлеге <*> | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Күрсәтмә законда каралган тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин. Шикаять кылу әлеге күрсәтмәнең үтәлешен туктатмый.

--------------------------------

<*> Тикшерелүче зат башкарырга тиешле конкрет чаралар күрсәтелә.

<**> Күрсәтмәләнүче бурычларны караган норматив-хокукый актка сылтамалар күрсәтелә.

Вазифаи затның вазифасы:

______________________________________ _____________ ___________________

(Ф.И.А.) (имзасы) (дата)

Күрсәтмә алынды


_____________________________________ ___________________________________


(шәхси эшмәкәрнең яисә тикшерелүче оешма җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең)Ф.И.А.)

шәхси эшмәкәрнең яисә тикшерелүче оешма җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең)имзасы)

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләренә карата җир асты биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан рациональ файдалануга һәм аларны саклауга карата төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентына карата 2 кушымта**

ДӘҮЛӘТ ВАЗИФАСЫН ҮТӘҮНЕҢ
БЛОК-СХЕМАСЫ




Актныэ бер нөсхәсен юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) вәкилләренә тапшыру яки кулга тапшыру турында тамга белән почта элемтәсе аша җибәрү
Вазифаи затның үткәрелгән документар тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә теркәве
Боерык (әмернамә) буенча урынга чыгып тикшерү үткәрү
Билгеләнгән таләпләрне бозу очракларын ачыклау
Билгеләнгән таләпләрне бозу очраклары булмауны ачыклау
Мәгълүматны дәүләт хакимияте органнарына аларның вәкаләте кысаларында җибәрү
Административ хокук турында эш кузгату
Административ хокук бозу эше буенча эш башкару
Урынга чыгып үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча акт, күрсәтмә төзү
Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча акт, күрсәтмә төзү
Юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең вәкилен, шулай ук күзәтчелек буенча чаралар үткәрүдә катнашкан затларны акт, күрсәтмә белән таныштыру
Нигезләмәләренең күчермәләре белән бергә актның, күрсәтмәнең бер нөсхәсен юридик зат белән шәхси эшмәкәрнең вәкилләренә тапшыру
Актны, күрсәтмәне, кулга тапшыру турында тамга белән, почта элемтәсе аша җибәрү
Вазифаи затның үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә язу теркәве

**Татарстан Республикасы Экология**
**һәм табигый ресурслар министрлыгында**
**җирле әһәмияттәге җир асты**
**кишәрлекләренә карата җир асты**
**биләмәләрен геологик өйрәнүгә, алардан**
**рациональ файдалануга һәм аларны**
**саклауга карата төбәк дәүләт**
**күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча**
**дәүләт вазифасын үтәүнең административ**
**регламентына карата 3 кушымта**
**(үрнәк рәвеше)**

Юридик зат (шәхси эшмәкәр) объектында (объектларында)
контрольлек итү буенча чаралар үткәрүнең
җаваплы башкаручылар, АКМИ белгечләре өчен
ПЛАН-БИРЕМЕ

ТР табигатьне саклау буенча баш дәүләт инспекторының (ТР табигатьне саклау буенча Баш дәүләт инспекторы урынбасарының) юридик зат (шәхси эшмәкәр) объектында (объектларында) контрольлек итү буенча чаралар үткәрү турында елның ___________ (дата) №________ боерыгы (әмернамәсе) нигезендә
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________:
(юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, Исеме һәм (булган очракта) атасының исеме)

1. Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтләнгән хезмәткәрләргә әлеге объектта (объектларда) чираттагы чараларны үткәрергә:

| Контроль буенча чара | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтләнгән аналитика контрольлегенең махсуслашкан инспекциясе белгечләренә объектта (объектларда) чираттагы чараларны үткәрергә:

| Контроль буенча чара | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

_____________________________________________ ____________________
(Баш җаваплы башкаручының ФИА, имзасы) (дата)